«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр
_____________ Р.Т. Борһанов
«_21_» _февраль_ 2020 нче ел

**Төп дәүләт буларак төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе (ТДИ)**

# География буенча 2020 ел төп дәүләт имтиханы

# контроль үлчәү материалларының үрнәк варианты

**“ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ”**

**Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе**

**тарафыннан әзерләнгән**

**Төп дәүләт буларак төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе (ТДИ)**

**География буенча 2020 ел төп дәүләт имтиханы контроль үлчәү материалларының үрнәк варианты**

**“ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ” Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнгән**



## ГЕОГРАФИЯ буенча төп дәүләт имтиханы

### ГЕОГРАФИЯ буенча 2020 ел төп дәүләт имтиханы контроль үлчәү материалларының демонстрацион вариантына аңлатма

2020 елның үрнәк варианты белән танышканда, үрнәк вариантның 2020 ел КҮМ вариантлары ярдәмендә тикшерелергә тиешле эчтәлекнең барлык варианларын да чагылдырмавын исәпкә алырга кирәк. Предмет эчтәлегенең 2020 нче елгы имтиханда тикшерелергә мөмкин булган элементлары төп дәүләт имтиханына укучыларны әзерләү дәрәҗәсенең эчтәлеге һәм куелган таләпләр элементының кодификаторында чагылыш тапкан. Ул www.fipi.ru. сайтына урнаштырылган.

Үрнәк вариант имтиханда катнашучыларга һәм киң җәмәгатьчелеккә имтихан эшенең структурасы, биремнәрнең саны һәм формасы, шулай ук катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру өчен кирәк. Имтихан эшенең үрнәк вариантында бирелгән киңәйтелгән җавапны таләп итә торган биремнәрнең үтәлешен бәяләү критерийлары киңәйтелгән җавапларны язуның тулылыгына һәм дөреслегенә куелган таләпләрне күзалларга ярдәм итә.

Әлеге мәгълүматлар имтиханда катнашачак укучыларга 2020 елда география буенча имтихан тапшыруга әзерләнүнең стратегиясен булдырырга ярдәм итә.

© 2020 Федеральная служба по надзору в сфере образования и науки

# ГЕОГРАФИЯ

**буенча 2020 ел төп дәүләт имтиханының контроль үлчәү материалларының үрнәк варианты**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Имтихан эше 30 биремнән тора. География буенча биремнәрне үтәү өчен 2,5 сәгать (150 минут) вакыт бирелә. 1 нче бүлеккә кыска җаваплы 14 бирем кергән, 2 нче бүлек киңәйтелгән җаваплы 7 биремнән гыйбарәт.

1, 4, 5, 6, 11, 16–18 биремнәргә җавапларны җавапның дөрес варианты номерына туры килгән бер цифр белән языгыз, аннан соң 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп языгыз.

2, 3, 7–10, 13–15, 19–27, 30 нче биремнәргә җаваплар сан, сүз (сүзтезмә) яки цифрлар эзлеклелеге рәвешендә языла. Җавабыгызны эш текстында бирелгән җавап урынына языгыз, аннан соң 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп языгыз. Һәр символны, бланкта китерелгән үрнәктәгечә, аерым шакмакларга языгыз. Цифрлар эзлеклелеге рәвешендәге җавапларны бланкккка күчергәндә (3,8,14,15, 19-21, 24-25 нче биремнәр), өтерләр, буш урын, башка төрле символлар кулланмыйча, әлеге эзлеклелекне генә чагылдырыгыз. Әгәр дә биремгә җавап үлчәү берәмлеге белән бирелсә, җавапны бланкка күчергәндә, килеп чыккан санны гына язарга кирәк. Үлчәү берәмлеген күрсәтү кирәк түгел.

Эштә киңәйтелгән җавапны таләп итә торган 3 бирем (12,28 һәм 29) бар. Бу биремнәрнең җаваплары 2 нче номерлы бланкта языла. Башта биремнең номерын, аннан соң җавабын языгыз.

Эшне башкарганда 7,8, һәм 9 классларның георафик атласларыннан, линейка һәм программалаштырылмаган калькулятордан файдаланырга рөхсәт ителә.

Барлык бланклар куе кара паста белән тутырыла. Гельле яки капиллярлы ручка куллану рөхсәт ителә.

Эшне башкарганда, караламадан файдаланырга ярый. **Эшегезне бәяләгәндә, караламадагы, шулай ук контроль бәяләү материаллары текстындагы язмаларыгыз исәпкә алынмаячак.**

Биремнәрне үтәгәндә алган балларыгыз бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

Эш тәмамланганнан соң, 1 нче һәм 2 нче бланкларда һәр биремгә җавапның дөрес номеры язылуын тикшерегез.

***Уңышлар телибез!***



**1** Түбәндә китерелгән объектларның кайсы Россиядә урнашкан?

1) дөньядагы иң озын елга
2) дөньядагы иң тирән күл
3) дөньядагы иң биек тау түбәсе
4) дөньядагы иң биек шарлавык

Җавап: ☐

**2** Буш урынга төшереп калдырылган дәүләт исемен языгыз.

Смоленск өлкәсе РФ се чик буе субъектларының берсе булып тора, ул РФ сенең ________________ белән булган Дәүләт чигенә чыга.

Җавап:________________.

**3** Россия регионнарын территорияләрендәге туфракта табигый уңдырышлылыкның кимүе тәртибендә урнаштырыгыз. Цифрларны таблицада шул эзлеклелектә урнаштырыгыз.

1) Архангельск өлкәсе
2) Смоленск өлкәсе
3) Воронеж өлкәсе

Җавап: | | | |

**4** Географ студентларга тикшеренүләр үткәрү өчен Россия далаларының Европа өлешендәге иң төньяк участокларында булырга кирәк. Студентлар түбәндәге тыюлыкларның кайсына барырга тиешләр?

1) Кандалакша
2) Ока буе террасалары
3) Таймыр
4) Астрахань

ЯКИ

Болан үрчетү, балыкчылык һәм диңгез хайваннары промыселы түбәндә китерелгән кайсы халыкның традицион шөгыле булып санала:

1) кареллар
2) чукчалар
3) марийлар
4) чувашлар

Җавап: ☐

***5 һәм 6 биремнәрне түбәндә бирелгән һава торышы картасына нигезләнеп башкарыгыз.***




**В** Югары атмосфера басымы өлкәсе
**Н** Түбән атмосфера басымы өлкәсе
Циклоннарның һәм антициклоннарның урыннарын алыштыру юнәлешләре
Җылы атмосфера фронты
Салкын атмосфера фронты
14...19 Һава температурасы
Яңгыр

**5** Картада чагылыш тапкан түбәндә китерелгән шәһәрләрнең кайсы циклон тәэсире зонасында?

1) Новороссийск
2) Салехард
3) Благовещенск
4) Төмән

Җавап: ☐



**6** Һава торышы картасы 27 апрельгә төзелгән. Картада чагылыш тапкан түбәндә китерелгән шәһәрләрнең кайсында алдагы көндә җылыту ихтималы зуррак?

1) Благовещенск
2) Абакан
3) Петрозаводск
4) Элиста

Җавап : ☐

**7** Россия Федерациясе составындагы республика башкаласы булган кайсы шәһәрнең географик координаталары 62° т.к. 34° көнч.озынлыкта?

Ответ:____________________________.

**8** Укучылар экскурсия вакытында карьерның текә ярында тау токымнары ятмаларының схематик рәсемен ясаганнар.




*валунлы комсыл балчык
известьташ
кварцит
гранит

Рәсемдә күрсәтелгән тау токымнары катламнарын яшьләре арту тәртибендә (иң яшеннән иң борыңгысына таба) урнаштырыгыз. Цифрларның килеп чыккан эзлеклелеген таблицага языгыз.

1) известьташ
2) валунлы комсыл балчык
3) кварцит

Җавап : 

| | | |
|---|---|---|
| | | |

***9–12 биремнәр түбәндәге топографик карта фрагментыннан файдаланып башкарыла.***




100 0 100 200

Масштаб 1: 10 000
В 1 см 100 м
Горизонтали проведены через 2,5 метра

* Каланча
Чишмә
Чиркәү
Шоссе
Катнаш урман
Болын

Горизонтальләр 2,5 м ара саен үткәрелгән

**9** Карта буенча чишмәдән чиркәүгә кадәрге туры юлдан булган араны билгеләгез. Үлчәүне шартлы билгеләрнең үзәкләре арасыннан үткәрегез. Нәтиҗәгезне дистә метрга кадәр түгәрәкләгез. Җавабыгызны сан белән языгыз.

Җавап:____________________________м.

**10** Карта буенча, чишмә каланчадан кайсы юнәлештә урнашуын билгеләгез.

Җавап:____________________________.



**11** Рәсемдә карта нигезендә А-В линияләре буенча төрле укучылар тарафыннан төзелгән урын рельефы профиленең вариантлары бирелгән. Профильләрнең кайсы дөрес төзелгән?




Җавап: ☐

**12** Фермер җиләк-җимеш бакчасы үстерү өчен җир эзли. Аңа язын кары иртә эри, җәен кояш туфракны бик яхшы җылыта торган участок кирәк. Участок шулай ук җыелган уңышны консерв заводына чыгару өчен дә уңайлы булырга тиеш. Картада 1, 2 һәм 3 цифрлары белән бирелгән участокларның кайсы әлеге таләпләргә җавап бирә. Җавабыгызны нигезләү өчен ике дәлил китерегез. Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремегезнең номерын күрсәтегез.

**13**

Балтыйк диңгезенең өске катламында суның тозлылыгы 8‰. Аның 3 литр суында ничә грамм тоз эрегәнен ачыклагыз. Җавабыгызны сан белән языгыз.

Җавап:________________________г.

**14**

Кар ишелмәләре – табигатьтәге иң дәһшәтле һәм иң куркыныч күренешләрнең берсе. Россиянең түбәндә китерелгән кайсы ике регионына кар ишелмәләре куркынычы яный? Таблицага регионнарны цифрлары белән язып куегыз.

1) Калининград өлкәсе
2) Төньяк Осетия Республикасы – Алания
3) Әстерхан өлкәсе
4) Архангельск өлкәсе
5) Камчатка крае

Җавап : [ ][ ]

**15**

Халык хуҗалыгында кеше тарафыннан башкарыла торган эшләрнең кайсы дала, урман-дала зоналарында калкулык битләрендә чокырлар барлыкка килүне туктата? Таблицага әлеге эшчәнлек чагылдырылган цифрны язып куегыз..

1) агачлар һәм куаклар утырту
2) мал көтү
3) территорияне буйга сөрү
4) минераль ашламалар файдалануны чикләү
5) калкулыкларны террасалау

Җавап: [ ][ ]



*16 һәм 17 биремнәр бирелгән текст нигезендә башкарыла*

Россиядәге берничә торак пунктның укучылары җирле метеостанцияләр тарафыннан теркәлгән күпьеллык мәгълүмат белән алмашканнар. Әлеге мәгълүматлар түбәндәге таблицада чагылган.

| күзәтү пункты | Күзәтү пунктының географик координаталар | Диңгез өсте тигезлегеннән, м | Һаваның июльдәге уртача температурасы, °С | Һаваның январьдагы уртача температурасы, °С | Атмосфера явым-төшемнәренең уртача еллык күләме, мм |
|---|---|---|---|---|---|
| Сортавала | 61° т.к.. 30° . көнч.о. | 17 | +16,4 | –9,8 | 570 |
| Вологда | 59° т.к. 40° көнч.о. | 125 | +17,0 | -11,9 | 568 |
| Балахна | 57° т.к. 44° көнч.о. | 63 | +19,0 | –11,6 | 542 |
| Уфа | 54°т. к. 56° көнч.о. | 104 | +19,5 | –15,0 | 569 |

Укучылар тапкан мәгълүматларны торак пунктның географик урыны белән климат үзенчәлекләре арасындагы бәйләнеш табу максаты белән анализап чыкканнар. Төрле укучыларның нәтиҗәләре төрлечә чыккан. Кемнең нәтиҗәсе дөрес?

1) Алина: « Көньяк -көнчыгышка киткән саен атмосфера явым-төшемнәренең еллык уртача күләме арта бара".
2) Сергей: « Көньяк -көнчыгышка киткән саен һава температурасының уртача еллык амплитудасы арта бара".
3) Георгий: «Төньякка киткән саен январь аенда һава температурасы түбәнрәк».
4) Тамара: «Торак пункт диңгез өсте тигезлегеннән биегрәк урнашкан саен июль аенда һава торышы салкынрак".

Җавап : [ ]

**17** Түбәндә китерелгән торак пунктларның кайсында көн уртасында җирле кояш вакыты белән 22 июльдә кояш нурлары төшү почмагы кечерәк булачак?

1) Сортавала
2) Вологда
3) Балахна
4) Уфа

Җавап: ☐

**18** Климатограмманы анализлагыз һәм анда чагылдырылган климатка хас характеристикалы пунктның картада нинди хәреф белән бирелүен ачыклагыз.







— границы климатических поясов

Климатик поясларның чиге

1) A  2) B  3) C  4) D

Җавап: : ☐



**19** Россия регионнарын анда яшәүче халыкның Яңа елны каршылау тәртибендә урнаштырыгыз. Килеп чыккан цифрлар эзлеклелеген таблицага языгыз.

1) Коми Республикасы
2) Чиләбе өлкәсе
3) Хабаровск крае

Җавап: ☐☐☐

**20** Россиянең төрле регионнарындагы туристик фирмалар үз регионнарына туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап тапканнар. Слоганнар һәм регионнар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элементны сайлап алыгыз.

| СЛОГАННАР | РЕГИОННАР |
|---|---|
| А) Монда күлләрнең иксез-чиксез киңлекләре, утраулар һәм Кивач шарлавыгы белән хозурланырга мөмкин! | 1) Карелия Республикасы |
| Б) Алтынкүлгә (Телецкое озеро) таудагы кабатланмас матурлыкка ия энҗе бөртегенә рәхим итегез! | 2) Краснодар крае |
| | 3) Алтай Республикасы |
| | 4) Самара өлкәсе |

Таблицага сайлап алган цифрны хәрефенә туры китереп язып куегыз.

Җавап:

| А | Б |
|---|---|
| | |

**21** Лена елгасы турында язылганнарның икесендә елганың режимы турында мәгълүмат бирелә. Табыгыз һәм аларны чагылдырган цифрларны таблицага язып куегыз.

1) Лenaның Витимга коюга кадәрге югары агымы таулы Байкал алдына туры килә.
2) 70 елга якын алып барган күзәтүләр Лена елгасында суның уртача еллык агышы 541 км³ .
3) Лена елгасы өчен язгы ташу һәм җәй буена берничә шактый көчле су күтәрелеше булу хас.
4) Лена елгасы, нигездә, эрегән кар суы һәм яңгыр сулары белән туена.
5) Октябрь азагында Лена боз белән каплана, ул май азагында гына эри.

Җавап: ☐☐

*22 һәм 23 биремнәр статистик мәгълүматларга таянып башкарыла*

**Международная миграция в России за период 2013–2018 гг.**

**2013 -2018 елларда Россиядә халыкара миграция**




**22** Графикта күрсәтелгән елларның кайсында Россиягә башка илләрдән даими яшәү өчен күчеп килүчеләр саны иң күп. Җавабыгызны сан белән языгыз.

Җавап:_____________ел

**23** Россиядә 2016 елда күчеп килүчеләр исәбенә халык саны арту күләмен билгеләгез. Җавабыгызны сан белән языгыз.

Ответ:______________________________кеше.



**24** Россиянең түбәндә китерелгән регионнарының кайсында халыкның уртача тыгызлыгы иң югары? Таблицага әлеге регионнарны чагылдырган цифрларны язып куегыз.

1) Камчатка крае
2) Ростов өлкәсе
3) Мурманск өлкәсе
4) Карелия Республикасы
5) Омск өлкәсе

Җавап: | | |

**25** Түбәндә китерелгән шәһәрләрне, аларда халык саны арту тәртибендә урнаштырыгыз. Килеп чыккан цифрлар эзлеклелеген таблицага язып куегыз.

1) Липецк
2) Новосибирск
3) Псков

Җавап: | | | |

**26** Түбәндә китерелгән шәһәрләрнең икесе алюминий промышленносте үзәге булып тора. Кайсылары? Таблицага әлеге шәһәрләрне чагылдырган цифрларны язып куегыз.

1) Красноярск
2) Ярославль
3) Петрозаводск
4) Череповец
5) Братск

Җавап: | | |

*27–29 биремнәр түбәндәге текстка нигезләнеп башкарыла*

**Җир шары тирәли Антарктика экспедициясе**

2016 елның декабрендә Кейптаун шәһәре портыннан җир шары тирәли Антарктика экспедициясе командасы озакка сузылган сәяхәткә чыгып китә, ул 2017 нче елның мартында төгәлләнә. Швецария Поляр институты һәм Россия география җәмгыятенең (РГҖ) масштаблы тикшеренү проекты булып тора. Экспедиция, заманча фәнни лабораторияләр белән җиһазландырылган, өстәмә йөзү чаралары һәм хәтта өч вертолёты булган “Академик Трешников” исемендәге Россия фәнни-тикшеренү судносында, билгеләнгән маршрут буенча уза. Суднода дөньяның төрле илләре университетларыннан 50 студент булып, алар “РГҖ ның диңгез экспедициясе” проектында катнаша. Проект кысаларында 25 көн дәвамында яшь белгечләр тәҗрибәле галимнәр җитәкчелегендә антарктик һәм субантарктик климат пояслары чикләрендә океанографик һәм гидрометеорологик тикшеренүләр уздыра.

**27** Җир шары тирәли Антарктика экспедициясе командасы озакка сузылган сәяхәткә кайсы дәүләт территориясеннән чыгып китә?

Җавап:_____________.

**28** Тикшеренүләр алып барылган акватория климатын нинди һава массалары төре формалаштыра?

Биремнең номерын күрсәтеп, җавабыгызны 2 нче номерлы җаваплар бланкына язып куегыз.

**29** Ни өчен экспедиция вакытында тикшеренү эшләре алып бару өчен иң уңай чор – декабрьдән-март айлары булуын аңлатыгыз.

Биремнең номерын күрсәтеп, җавабыгызны 2 нче номерлы җаваплар бланкына язып куегыз.

**30** Кыскача тасвирламасы буенча Россиянең кайсы регионы булуын билгеләгез.

Бу өлкә илебезнең Европа өлешенә урнашкан һәм чит илләр белән чиктәш. Территориясенең күпчелек өлеше Поляр түгәрәк артында урнашкан. Аның



территориясендә тимер рудасы һәм төсле металл рудалары булу аеруча зур әһәмияткә ия. Өлкәнең территориясендә эре АЭС эшли.

Җавап:__________________________ өлкәсе.

***Һәр җавабыгызның биремгә тәңгәл килгән номеры янына язылган булуын тикшерегез.***

**География буенча имтихан эшен бәяләү системасы**

1–11, 13–27, 30 биремнәрне дөрес башкарган өчен 1 балл куела. Әгәр дә таләп ителгән бер-ике сүз, сан, цифр яки цифрлар эзлеклелеге дөрес күрсәтелсә, бирем дөрес эшләнгән булып санала.

| Биремнең номеры | Дөрес җавап | |
|---|---|---|
| 1 | 2 | |
| 2 | Белоруссия | |
| 3 | 321 | |
| 4 | 2 | 2 |
| 5 | 3 | |
| 6 | 1 | |
| 7 | Петрозаводск | |
| 8 | 213 | |
| 9 | 400; 410; 420; 430; 440 | |
| 10 | С; Төньяк; төньякта | |
| 11 | 4 | |
| 13 | 24 | |
| 14 | 25 | |
| 15 | 15 | |
| 16 | 2 | |
| 17 | 1 | |
| 18 | 2 | |
| 19 | 321 | |
| 20 | 13 | |
| 21 | 35 | |
| 22 | 2015 | |
| 23 | 261 948 | |
| 24 | 25 | |
| 25 | 312 | |
| 26 | 15 | |
| 27 | ЮАР | |
| 30 | Мурманск | |

**Киңәйтелгән җавап таләп итә торган биремнәрне бәяләү критерийлары**




**12** Фермер җиләк-җимеш бакчасы үстерү өчен җир эзли. Аңа язын кары иртә эри, җәен кояш туфрагын бик яхшы җылыта торган участок кирәк. Участок шулай ук җыелган уңышны консерв заводына чыгару өчен дә уңайлы булырга тиеш. Картада 1, 2 һәм 3 цифрлар белән бирелгән участокларның кайсы әлеге таләпләргә җавап бирә. Җавабыгызны нигезләү өчен ике дәлил китерегез.

Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремегезнең номерын күрсәтегез.



| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның, мәгънәсен бозмый торган булса, башка формулировкасы да булырга мөмкин) | **Баллы** |
|---|---|
| Җавапта күрсәтелгән таләпләргә иң нык җавап бирә торган участок булып<br>1) 2 участок тора.<br>Нигезләмә итеп түбәндәге дәлилләр китерелә:<br>2) бу шоссега иң якын торган участок;<br>3) участок көньяк экспозиция сөзәклегендә урнашкан; | |
| Җавапта югарыда китерелгән 3 элемент чагылыш тапкан | 2 |
| Җавапта югарыда китерелгән 2 (1 нче һәм 2 нче яки 1 нче һәм 3 нче) элемент чагылыш тапкан.<br>ЯКИ Җавапта 1 нче элемент юк, ләкин куелган таләпләргә иң нык җавап биргән участокның 1 нче булуы әйтелә һәм, нигезләгәндә, 2 нче элемент китерелә.<br>ЯКИ Җавапта 1 нче элемент бирелми, куелган таләпләргә иң нык җавап биргән участокның 3 нче булуы әйтелә һәм, нигезләгәндә, 2 нче элемент китерелә.<br>ЯКИ Җавапта 1 нче элемент бирелми, ләкин сөзәклекләрнең экспозициясе һәм картада чагылдырыган һәр участокның шоссега мөнәсәбәтле урнашуы дөрес күрсәтелгән. | 1 |
| 1 һәм 2 балл белән бәяләп булмаган барлык башка җаваплар | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

## Җир шары тирәли Антарктика экспедициясе

2016 елның декабрендә Кейптаун шәһәре портыннан җир шары тирәли Антарктика экспедициясе командасы озакка сузылган сәяхәткә чыгып китә, ул 2017 нче елның мартында тәгәлләнә. Швецария Поляр институты һәм Россия география җәмгыятенең (РГЖ) масштаблы проекты булып тора. Экспедиция, заманча фәнни лабораторияләр белән җиһазландырылган, өстәмә йөзү чаралары һәм хәтта өч вертолёты булган “Академик Трешников” исемендәге Россия фәнни-тикшеренү судносында, билгеләнгән маршрут буенча уза. Суднода дөньяның төрле илләре университетларыннан 50 студент булып, алар “РГЖ ның диңгез экспедициясе” проектында катнаша. Проект кысаларында 25 көн дәвамында яшь белгечләр тәҗрибәле галимнәр җитәкчелегендә антарктик һәм субантарктик климат пояслары чикләрендә океанографик һәм гидрометеорологик тикшеренүләр уздыра.

**28** Тикшеренүләр алып барылган акватория климатын нинди һава массаларының төре формалаштыра?

Биремнең номерын күрсәтеп, җавабыгызны 2 нче номерлы җаваплар өчен булган бланкка язып куегыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның , мәгънәсен бозмый торган булса, башка формулировкасы да булырга мөмкин) | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта антарктик һәм урта һава массалары турында әйтелә | |
| Җавапта югарыда күрсәтелгән элемент бар | 1 |
| Барлык җаваплар да югарыда китерелгән 1 балл белән бәяләнерлек критерийга туры килми | 0 |
| *Максималь балл* | *1* |



**29** Ни өчен экспедиция вакытында тикшеренү эшләре алып бару өчен иэ уңай чор – декабрь-март айлары булуын аңлатыгыз.

Биремнең номерын күрсәтеп, җавабыгызны 2 нче номерлы җаваплар өчен булган бланкка язып куегыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның , мәгънәсен бозмый торган булса, башка формулировкасы да булырга мөмкин) | **Баллы** |
|---|---|
| Җавапта декабрь – март айларында Көньяк ярымшарда җәй булуы турында әйтелә<br>ЯКИ<br>Декабрь – март айларында навигация өчен иң уңай шартлар күзәтелүе<br>ЯКИ<br>Декабрь – март айларында Көньяк ярымшарда поляр түгәрәктән көньякка таба поляр көн күзәтелүе турында әйтелә | |
| Җавапта югарыда әйтелгән элемент бар | 1 |
| 1 балл белән бәяләп булмаган барлык башка җаваплар | 0 |
| *Максималь балл* | *1* |

Төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе нигезендә (Россия Мәгариф министрлыгы һәм Рособрнадзорның 07.11.2018 № 189/1513 боерыгы, Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан 10.12.2018 № 52953 теркәлгән.)

«64. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә.Экспертлар, бер-берсеннән бәйсез рәвештә, тикшерү нәтиҗәләре буенча имтихан эше биремнәренә һәр җавап өчен баллар куя. Ике эксперт куйган балларда сизелерлек аерма булган очракта, өченче тикшерү билгеләнә. Балларда сизелерлек аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Элек имтихан эшен тикшермәгән экспертлардан өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе итеп билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен тикшергән экспертлар тарафыннан куелган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргы булып тора».

Ике эксперт тарафыннан 12 биремне үтәү өчен куелган баллар арасындагы аерманы 2 балл тәшкил итү зур аерма санала. Өченче эксперт баллар арасындагы аерманы китереп чыгарган 12 бирем җавабын гына тикшерә.